# «Үлгәннәр хәтере исәннәрдә яши»

**( Багышлана Хәбибрахманов Нурылхак Хәбибулхак улына Балтач районы Түбән Шубан авылында яшәгән)**

Әфган. Илебез тарихының әрнүле, кайгылы бер бите. Күкләргә тиеп утырган таулар арасында үлем белән күзгә–күз очрашкан язмышлар. Меңләгән үлемнәр күргән, меңләгән алданган һәм җимерелгән хыяллар иле.

Хәбибрахманов Нурылхак абый 1960 нчы елның 26 ноябрендә Балтач районы Түбән Шубан авылында 3 нче бала булып туа. 1967 елда Шубан башлангыч мәктәбенә укырга керә. 1977 елда Карадуган урта мәктәбен тәмамлаганнан соң колхозда тракторист булып эшли.

1978 елның октябрендә военкомат кушуы буенча Казанда хәрби техника (тягачка) укып, 1979 елның февраль аенда механик–йөртүче белгечлеге алган.

1979 елның 10 апрелендә военкоматтан чакыру кәгазе килә һәм Нурылхак абый башта Германиягә барып эләгә. Анда укый, хәрби хезмәтнең нечкәлекләренә өйрәнә. Алты айдан соң аларны частьларга тараталар.


1979 елның декабрендә солдатларны Германиядән үзләренең танклары белән Белорусиягә чыгарганнар. 1980 елның гыйнварендә танк белән Үзбәкстанга китәләр. Шул ук елны Үзбәкстаннан танклар тизлеге белән Әфган башкаласы Кабулга керәләр.



Үзе турында хатларында ул болай дип яза: «Минем хәлләргә килгәндә үзем әлегә бер килеш кенә служить итеп йөрим. Служба бер җайга уза. Шулай ук Рафикъ та бер килеш служить итеп йөри. Алдагы хатларда язганча шул иске урында».

1980 елның февраленнән 1981 елның маена кадәр шунда хезмәт итә һәм 1981 елның 27 маенда исән-сау туган авылына кайтып тракторист булып эшли.

Нурылхак абыйның вазыйфасы һәм хәрби исеме: сержант булган. Хезмәт иткән вакытта сигез тапкыр сугыш хәрәкәтендә катнашырга туры килгән, әмма абыем ул турыда сөйләргә яратмаган. Алай да әнисе белән ялгызы гына калгач ул: «Нәнә, мин бик бәхетле, бер чакны танк белән тауларга күтәрелгәндә танк кинәт артка-упкынга таба тәгәри башлады һәм кинәт туктап калды. Безне упкынга очудан чәйнек кадәр генә таш саклап калды,»- дип искә алган. Чынлап та ул бәхетле, өзелеп көткән әнисен, туганнарын күрә. Яшьли гомере өзелсә дә, аның сөякләре Әфган җирендә таралып калмаган, туган авылы зиратында кабере бар.Туганнары еш кына килеп анда чәчәкләр үстерәбез.



Егетлек бурычын үтәп кайткан  сөлектәй абыем кызганычка каршы 1983 елны 22 яшендә вакытсыз үлем белән арабыздан китеп бара.

Еллар үтү белән күп вакыйгалар хәтердән җуела. Үлгәннәр хәтере исәннәрдә яши. Абыебызның соңгы истәлекләре булып, өйдәгеләрен сагынып, туган якларын җирсеп язган хатлары һәм фотолары гына калды.

Эшләде: Хәбибрахманов Айнур
Альберт улы (12 яшь)
Шубан төп гомуми белем мәктәбе
6 нчы сыйныф укучысы
Балтач районы Түбән Шубан авылы.